Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге составына керүче Киса авылында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 30 ноябре № 10

««Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлегенең Киса торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.2020 елда Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Киса авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, гражданнар өчен 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Кисы торак пункты чикләрендә юл полотносы булдыру;

- Киса торак пункты эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту.

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп);

- Киса торак пунктының урам яктыртуын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

3) җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын үткәрүне тәэмин итү;

- мотопомпа сатып алу;

3. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubaevo.tatar.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

СОВЕТ НОВОАКСУБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы М. М. Сөләйманкин